ГЛАВА МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 ноябрь, 2025 ел Мөрәле ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 21 ноябрендә 11 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 70А йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә
2. 2025 елның 22 ноябрендә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Яшьләр ур, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2025 елның 24 ноябрендә 10 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 45нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә .
4. 2025 елның 25 ноябрендә 10 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Гагарин ур., 14а нче йорт адресы буенча урнашкан “Ак каен” кибете янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылы территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500

(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау ( шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер СИП чыбыклары сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү(шул исәптән торак пункт территориясен чаптыру);
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?».

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://muralin-kaybici.tatarstan.ru./ урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин